




СӘЛИМӘ ШӘРИПОВА

ГҮЗӘЛЕМ ЧАЛЛЫ

Кама буйлары таллы,
Карап күзләрем талды.
Иркәм биргән кулъяулыкны
Шул таллар алып калды.
Әй, гүзәлем, Чаллы, Чаллы,
Йөрәкнең янган чагы.
Бу йортта зур өмә икән,
Яшь кызлар килә икән.
Шуңа егетләр баскычны
Мәрмәрдән тезә икән.
Өмәдәге моңлы җырлар
Үзәкне өзә икән.
Бакчаларга гөлләр чәчтем,
Таңнар аткан чагында.
Сандугачлар оя корсын
Сөйгән калам Чаллыда.
Киткән кошлар сагындырып
Кайтыр безгә тагын да.

55

**Сәлимә Шәрипова**

**Гүзәлем Чаллы**

Кама буйлары таллы,

Карап күзләрем талды.

Иркәм биргән кулъяулыкны

Шул таллар алып калды.

Әй гүзәлем, Чаллы, Чаллы,

Йөрәкнең янган чагы.

Бу йортта зур өмә икән,

Яшь кызлар килә икән.

Шуңа егетләр баскычны

Мәрмәрдән тезә икән.

Өмәдәге зур җырлар

Үзәкне өзә икән.

Бакчаларга гөлләр чәчтем,

Таңнар аткан чагында.

Сандугачлар оя корсын

Сөйгән калам Чаллыда.
Киткән кошлар сагындырып
Кайтыр безгә тагын да.